| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>Табарлинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Тәбәрле авыл җирлеге<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 Тәбәрле авылы № 13-4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип таныргa:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрлеавыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2013 елның 16 сентябрендәге 17-1 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2013 елның 16 сентябрендәге 17-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрлеавыл җирлеге Советының 2021 елның 10 июнендәге 9-1 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тәбәрле авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 28 мартындагы 11-3 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советының «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 16 августындагы 11-2 номерлы карары 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тәбәрле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002519

Р.Р.САЛИМУЛЛИН